ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2025 п.г.т.Алексеевское № 453

**Башкарма комитетның 07.05.2024 ел, № 175 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, инвалидлар яши торган, муниципаль торак фонды составына керүче күпфатирлы йортларда, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче өйләрдә инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм чаралар планын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы карары, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 06.02.2017 ел, № 21/о «Муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче өйләрдә инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм аның эш тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә һәм кадрлар алмашынуга бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Башкарма комитетның 07.05.2024 ел, № 175 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, инвалидлар яши торган, муниципаль торак фонды составына керүче күпфатирлы йортларда, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче өйләрдә инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм чаралар планын раслау турында» карарына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча:

http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_15.10.2025 ел,_ № _453_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, инвалидлар яши торган, муниципаль торак фонды составына керүче күпфатирлы йортларда, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче өйләрдә инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Хәмзина Е.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мельников Е.Н. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Семина Н.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге директоры,<br>комиссия секретаре (килештерү буенча); |
| Солдатова М.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Фомина Н.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Богатов Н.А. | «Идарәче компания» ҖЧҖ директоры (килештерү буенча); |
| Сюндюкова Е.А. | Татарстан Республикасы Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы иҗтимагый оешмасының Алексеевск районы оешмасы рәисе (килештерү буенча); |
| Шәяхмәдова А.Р. | Татарстан Республикасы буенча махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү «Защитники Отечества» дәүләт фонды филиалының инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килештерү буенча); |
| Плотникова Н.А. | Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү «Защитники Отечества» дәүләт фондының социаль координаторы (килештерү буенча); |
| Хафизов И.И. | «Мир, доступный для всех» БИО ИСҮ эксперты (килештерү буенча); |

| | |
|---|---|
| ________________ | Алексеевск муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килештерү буенча). |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**